| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 март 2014 ел № 7-2/т

Казан
шәһәре

***Татарстан Республикасының Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләргә.
2. “Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” 04 март, 2011 ел, № 7-8/т Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 06 март 2014 ел № 7-1/т карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифы

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта | озак вакыт куллану билеты белән бару өчен түләм | |
| | | 1 баруга[1] | 50 тапкыр бару[2] |
| Автобус | 17 | 16 | 15 |

<1> билгеле бер бәягә барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> билгеле бер вакыт аралагында билгеләнгән тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару өчен аерым транспортта бару бәясенә өстәп түләнелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге